**СОВЕТ АЛЬДЕРМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422711, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Альдермыш, ул. Хабибуллина, 25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422711, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Әлдермеш авылы, Хабибуллин ур., 25

Тел./факс: +7(84365) 79-4-03, e-mail: Alder.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**27 декабря 2018 года** **№ 142**

**«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 15 октябрендәге 9 номерлы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 сентябрендәге 286-ФЗ номерлы, Әлдермеш авыл җирлеге Уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге советы нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районының 15.10.2015 № 9 Әлдермеш авыл җирлеге советы карарына (Советның 2018 елның 30 апрелендәге 106 номерлы, 2018 елның 23 августындагы 116 номерлы карары редакциясендә) «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2 пунктчасының 2 абзацында -фатирларны сүзләреннән соң ^ сүзләрен өстәргә;

«, фатирлар өлешләре;»;

1.2 пунктның 3 подпунктындагы 1 абзацта - торак йортлардан соң «, торак йортлар өлешләре» сүзләрен өстәргә;»;

1.3. түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт өстәргә:

«3.1. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән ата-ананың берсенең (уллыкка алучылар, опекуннар, попечительләр) физик затлар мөлкәтенә салымны түләүдән азат итәргә, аның белән бергә 18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк бала яши.

Салым ташламасы салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган һәр төр салым салу объектына карата бирелә: салым түләүче милкендәге һәм эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган фатир (бүлмә) яисә торак йорт (торак йорт өлеше).

Салым ташламасы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә даими яшәүче (теркәлгән) салым түләүчеләргә бирелә.

Салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда билгеләнгән салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турындагы гаризаны үз сайлавы буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Т.С.Сабиров